КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 30 март г.Казань № 254

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2024 елларга Татарстан Республикасында «Мәгариф» илкүләм проекты кысаларында төбәк проектлары паспортларын раслау турында» 2018 ел, 13 декабрь, 1131 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2024 елларга Татарстан Республикасында «Мәгариф» илкүләм проекты кысаларында төбәк проектлары паспортларын раслау турында» 2018 ел, 13 декабрь, 1131 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карар исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2019 – 2024 елларга Татарстан Республикасында «Мәгариф» илкүләм проекты кысаларында төбәк проектларын раслау турында»;

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Президентының «2024 елга кадәр Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары һәм стратегик бурычлары турында» 2018 ел, 7 май, 204 нче Указын, Россия Федерациясе Президенты каршындагы Стратегик үсеш һәм илкүләм проектлар буенча совет президиумы тарафыннан расланган «Мәгариф» илкүләм проекты паспортын (2018 ел, 3 сентябрь, 10 нчы беркетмә), «Мәгариф» илкүләм проекты буенча проект комитеты утырышының 2018 ел, 7 декабрь, 3 нче беркетмәсе белән расланган «Мәгариф» илкүләм проектының федераль проектлары паспортларын тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

1 нче пунктның икенче, тугызынчы абзацлары үз көчен югалткан дип санарга;

әлеге карар белән расланган 2019 – 2024 елларга Татарстан Республикасында «Мәгариф» илкүләм проекты паспорты үз көчен югалткан дип санарга;

әлеге карар белән расланган 2019 – 2024 елларга Татарстан Республикасында «Мәгариф» илкүләм проекты кысаларында «Заманча мәктәп» проекты паспортын (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә;

әлеге карар белән расланган 2019 – 2024 елларга Татарстан Республикасында «Мәгариф» илкүләм проекты кысаларында «Һәр баланың уңышы» проекты паспортын (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә;

әлеге карар белән расланган 2019 – 2024 елларга Татарстан Республикасында «Мәгариф» илкүләм проекты кысаларында «Балалары булган гаиләләргә ярдәм күрсәтү» проекты паспортын (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә;

әлеге карар белән расланган 2019 – 2024 елларга Татарстан Республикасында «Мәгариф» илкүләм проекты кысаларында «Цифрлы мәгариф мохите» проекты паспортын (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә;

әлеге карар белән расланган 2019 – 2024 елларга Татарстан Республикасында «Мәгариф» илкүләм проекты кысаларында «Киләчәк укытучысы» проекты паспортын (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә;

әлеге карар белән расланган 2019 – 2024 елларга Татарстан Республикасында «Мәгариф» илкүләм проекты кысаларында «Яшь профессионаллар (һөнәри белем бирүнең көндәшлек сәләтен арттыру)» проекты паспортын (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә;

әлеге карар белән расланган 2019 – 2024 елларга Татарстан Республикасында «Мәгариф» илкүләм проекты кысаларында «Һәркем өчен яңа мөмкинлекләр» проекты паспорты үз көчен югалткан дип санарга;

әлеге карар белән расланган 2019 – 2024 елларга Татарстан Республикасында «Мәгариф» илкүләм проекты кысаларында «Социаль активлык» проекты паспортын (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры                                                                                    А.В.Песошин